**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Троицко-Урайского**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
422649, Республика Татарстан, Рыбно-Слободский район, с.Трой-Урай,ул.Прикамская, д.9

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Трой-Урай авылҗирлеге**
**Башлыгы**
422649, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Трой-Урай авылы, Кама буе урамы,9 йорт

Тел.: (84361) 24320, факс: (84361)24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

16.11.2023 Трой-Урай №1

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Трой-Урай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 27 ноябрь 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. 2023 елның 27 ноябрь 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

3. 2023 елның 27 ноябрь 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

4. 2023 елның 27 ноябрь 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә.

5.Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Трой-Урай, Гремячка авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку

йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

-Трой- Урай авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

-Трой- Урай, Гремячка авылларында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм Гремячка авылында су башнясы, скважина мәйданчыгынын коймасын ремонтлау (шартнамә буенча материаллар сатып алу, эшләр өчен түләү)

-Трой-Урай авылындагы скважина бинасын ремонтлау

- Авыл җирлеге торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр сатып алу, түләү)

- Авыл җирлегенең торак пунктларында территорияләрне төзекләндерү.

- Су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү (Техник паспортлар, су башняларына техник планнар ,Троицкий Урай һәм Гремячка авыллары скважиналарын эшләү)

-Трой-Урай авылында чүп-чарның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау

- Авыл җирлегенең «Аншлага» сын әзерләү һәм урнаштыру.

«каршы» «риза»

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама – буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районынын
Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин